*МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ*

# “Карга боткасы” тәмле икән

Похвистнево районының Яңа Мансур авылында “Карга боткасы” дип аталган милли бәйрәмебез үткәрелде. Элек ул татар-башкорт халыкларының яз башында уздырыла торган иң зур бәйрәме булган. Алар кара каргалар канат очларында язны алып киләләр, дип ышанганнар. Бу көнне балалар матур кием киеп, өй саен йөреп, йомырка, май, ярма, сөт җыйганнар, халыкны, җырлап-биеп, бәйрәмгә чакырганнар. Авылдашлар су буендагы калкурак урында учак кабызып, карга боткасы пешергәннәр. Изелеп пешкән тары боткасын башта Җиргә салганнар һәм аңардан дөньяларның тыныч булуын, мул уңыш сораганнар. Ботканың икенче кашыгы терлек һәм үсемлекләрне туендыручы суга агызылган, өченчесе - кояшлы көннәр бирүче һавага, ә дүртенчесе язны алып килүче кара каргаларга ашатылган. Шуннан соң гына ботка авыл халкына таратылган...

Менә шундый матур бәйрәмне гамәлгә кайтаргannar да инде Яңа Мансурда. Ул ике көн дәвам итте: башта Мәдәният йортында Бадыя Арысланованың оста куллары белән күз явын алырлык итеп бәйләнгән курчаклары, җанварлары, панно, күлмәк-башлыклары күргәзмәсе күрсәтелде. Бу эштә шулай ук катнашкан Саткынай Гафурова, Мәдинә Арысланова, Фәридә Гафиятуллина, Зәмзәмия Әхмәтҗанова, Сабина Әзамоваларның кул эшләренең дә чын осталарча башкарылганы күренеп торды. Өйрәнергә теләүчеләргә шунда ук мастер-класслар үткәрелде. Аннан соң күргәзмәне караучылар өйләреннән пешереп алып килгән бәлеш-кыстыбыйлары белән тәмләп чәй эчтеләр һәм Мәдәният йорты директоры Мөдәррис Фәхретдиновка, сәнгать җитәкчесе Рәшидә Фәйрушинага, социаль үзәк җитәкчесе Галимҗан Шәяхмәтовка, күргәзмәне оештыручыларның барысына да рәхмәт әйтеп, таралыштылар.

Ә икенче көнне “Карга боткасы” бәйрәме авылдашларны тагын Мәдәният йорты янына җыйды. Башта авыл үзешчәннәре бик зур һәм матур концерт күрсәттеләр. Тамашачылар залдан чыгуга Фәридә ханым Фәхретдинова зур казаннарда ботка да пешереп куйган, элеккеге вакытлардагыча күмер белән җылытыла торган самавырларда чәй дә кайнаткан иде. Авыл җирлеге башлыгы Ирек Газиев үзе дә кулына ботка салынган савыт тоткан, авылдашларын да боткадан авыз итәргә чакыра.

Менә шулай Яңа Мансур халкы борынгы йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне гамәлгә кайтарып, рәхәтләнеп “Карга боткасы” бәйрәмендә язны каршылады.

**Әкълимә СУБЕЕВА,**
**ветераннар советы рәисе.**
Яңа Мансур авылы,
Похвистнево районы.



**Авыл җирлеге башлыгы Ирек ГАЗИЕВ** (алгы планда) **карга боткасын өләшә.**

*ХИКӘЯ*




**(Ахыры. Башы үткән саннарда)**

Бигрәк тә кышның озын төннәрендә ялгыз каласы килми аның. «Миңа да иптәш булырсың, тәмләп чәй эчерермен, куныш кына кал инде, балам», - дип ялвара торган иде. Әлләбелеп, әллә инде саташып, төннәр буе үз-үзе белән сөйләшеп чыга. «Әй, балам, Бәдыйгуллам, кемнәргә дип ташлап киттең газиз әнкәңне», – ди. «Уч төбемдә калып ятим үскән идең ләбаса, кайларда гына кагылып-сугылып йөрисең икән, бәбкәм», - ди. Йә кинәт төн урталарында «әгүзе бисмилла»лар әйтеп, «төф-төф»ләр килеп өшкеренгәли, догалар укырга керешә. Таң атмастан алда торып намазлык өстенә иелсә дә, һаман сыкрану, сызлану сүзләрен ишетәсең. «Әй, балам, бу суыкта юка шинел белән өшисеңдер инде. Үзәккәйләреңә үтәдер... Аллам. Җылы өемдә дә менә әчемә бер дә җылы керми лә, бәбкәм. Күкрәгемә бозны илән кенә торалар ла. Син, балакаем, өшеп туңганнар анаң бәгыренә төшәдер лә инде», - ди иде.

Шулай сыкрана-сыкрана көндә җиңү хәбәре килүен, сугыш бетүен көтте Хупҗамал әби. Явыз «ярман»ны үз җирендә дөмбәсләүләр инде, дигәч, әбекәйнең бит җыерчыклары язылып китәрләр, сүнеп барган карашыннан яз нуры сирпелеп куйгандай булыр иде.

Әйе, шулай өметләнеп яши-яши ул сугышның соңгы кышын да уздырып җибәрде, һаман көннәр озынаюын исәпләп, «унда уйнатыр, унбердә борын канатыр, уникедә җиз табан, унөчтә күк табан, ундүрттә сөр сабан була, ә сабан сөргәндә җылытыр, Ходаем кушса», - дип көтте. Ләкин ул көнгә җитешә алмыйча, шул «күк табан» вакытында - гөрләп гөрләвекләр аккан чакта дөнья куйды ул.

Хәер, җәйне күрү түгел, Бәдыйгулла бәбкәсенең -«ездовой Зәбиров»ның командиры гәүдәсен каплап калып һәлак булу хәбәрен дә ишетергә туры килмәде аңа. Ул яман хәбәр килгәнче язгы кар сулары, апрель томаннары Хупҗамал әбине гүр иясе иткәннәр иде инде.

Дүрт ел буе көткән шатлыклы көннәр Байтирәккә килеп җиттеләр. Җиңү сөенечен беренче булып авыл Советы йортын каравыллап төн кунган Сәкинә апа таратты. Таң беленүгә үк, юл тузанында иске галош эзе калдырып, ул өйдән-өйгә чабулады. «Пәбидә, кызлар! Йоклап ятмагыз, пәбидә! Сугыш беткән!» - дип аваз салды бөтен авылга. Ул бәйрәм таңында бары тик Хупҗамал әбинең бушап калган өендә генә әлеге хәбәргә сөенүче булмады...

**IV**

- Ә мин бу көнне Пруссия чигендә, госпитальдә идем әле, - дип куйды Шаһиәхмәт абзый. - Никтер ул көн бик уелып истә калмаган.

Сугышка без атаң белән бер көнне аның машинасында киттек бит. Туп-тулы бер машина иек, ә авылга менә ватылып-җимерелеп берүзем кайттым. Алай буласын кем белгән бит. Барганда гел бәйрәм җырлары гына җырлап барган идек. Укытучы Хәбиб башлый, без, «җиңмәс көч юк» дип, күтәреп алабыз. Ул да бик еракта ятып калды, бахыр.

Шаһиәхмәт абзый иптәшләренең кайларда сугышып йөрүләрен, кемнең ничек үлеп калуын искә төшерде дә үз фикерен тәгәлләгәндәй итеп:

- Да, малай, егетнең егетләре харап ителде. Арадан мин бәхетле булдым. Бу очракта Аллага мең шөкер диясе генә кала, - дип, сүзен йомгаклап куйды.

Без инде Иртәк үзәненнән Очлытау иңенә күтәрелгәнбез. Шаһиәхмәт абзыйның хат һәм газеталар - шатлык һәм бәхет хәбәрләре белән тулы «казна» зур сумкасы күптән хуш исле тугай печәне астына күмелеп калган.

Урам-тыкрыкларны бизәп үскән өянке-тирәкләр арасыннан мин түземсезләнеп, ашкынып үз урамыбызны, «үз» йортыбызны эзлим. Инеш күперен үтүгә мин әүвәлгечә һаман читән капка төбендә утырган Шәфикъ бабайны, җелт-җелт атлап килгән Гөлдәминә, шук холыклы Бәдүкләрне очратырмын сыман. Шаһиәхмәт абзыйны күргәч тә, бая кемгәдер охшаткан идем. Шәфикъ бабайга охшаткан ләбаса. Тырма тотып килсәң - сапларга, чалгы китерсәң - шундук сугып бирергә әзер торган игелекле Шәфикъ бабай улы икән Шаһиәхмәт абзый.

- Булмас шул, әткәйне дә, Бәдүк абыеңны да, тагын бик күпләрне очрата алмассың хәзер авылда. Юк инде алар. Ә Гөлдәминәне күрерсең, шәй. Күрерсең дә, танырсың да. Бер дә картаймый ул, һаман шулай шат, көләч кыяфәтле. Ә бит биш бала анасы. Ирдән уңды ул, шул картаймый аны.

Гаҗәп бу дөнья. Бәдүктәй ишен югалткач, инде ул бәндә гомергә башын күтәрә алмас, шулай боегып сулгандыр, дип уйлыйсың. Юк, алай түгел шул ул тормыш.

Әйе, Гөлдәминәнең, мин белгән авыл күрке Гөлкәйнең үзгәрүе дә, кияүгә чыгуы да ихтимал. Шулай да мин аның Бәдүгеп онытуына ышанмыйм. Истән чыкмас андый яшьлек хисе, андый мәхәббәт. Тиз генә йөрәктән алып ташлардай егет түгел иде шул Бәдүк. Шуңа күрә дә аның Гөлкәе соңлап кына, бөтенләй чит-ят кешегә кияүгә чыккандыр да әле. Үз авылының, үзенең Бәдүген оныта алмаганга, шулай иткәндер.

*Күбәләк гөлләргә кунса,*
*Гөлләр тибрәнә микән?* - дип кем дә булса җыр башласа, күз алдымда арыш саламы өстенә сузылып яткан моңсу кыяфәтле Бәдүк төсмерләнә башлый. Бәдүк һаман исәндер, җырлый-моңая һаман да каядыр еракта, туган авылына кайтырга тилмереп кенә йөридер кебек хис ителә. Бу хәл, бәлкем, үземнең дә күптән читтә йөрүемә бәйледер. Шәй, юксынып, капка төбендә көтеп утыручысы булмаганга шулай уйланыладыр...

Без авыл башына ук килеп җиткәнбез. Түбән очтан, мөгри-мөгри, зур көтү күтәрелеп килә. Аксыл тузан болыты калдырып, урамнардан эшлекле машиналар узып киткәли. Анда-санда бала-чаганың йөгереп үткәне күренә. Инеш буасы ягында, тал-тирәк тирәсендә тартай моңланганы ишетелеп кала. «Тарт-тай, тарт-тай». Юк! «Кайттай, кайттай», дип һәр кайткан кешене элеккечә үк санап, исәпләп торадыр шикелле ул.

- Карале, тартай һаман исән икән! - дип әйтеп куйганымны үзем дә сизми калдым.

- Һе, алар бит үзара сугышмый, - диде Шаһиәхмәт абзый. Аннары күк биянең сыртына тидермичә генә, чыбыркысын болгап алды. Ат, инде ялыккан булса да, тизрәк авылга керергә ашкына иде ахрысы. Юыртып кына инеш күперенә таба китте.

*1 АПРЕЛЬ – КӨЛКЕ КӨНЕ*

# Ышанам шул...

Нишләтәсең, йолдызларга ышанам шул, фаразларын көтеп алам.

Апрель башындагысын укып карасам, акка кара белән: «Бу атна сезгә зур табыш китерер», - дип язылган. Уйга калдым. «Кайдан, нинди табыш булыр икән бу?!» - мин әйтәм. Гаҗәпләнерлек тә: артык бер тиен керер җирең булмасын, ә монда - табышның да зурысы! Кем төшереп калдырыр икән аны? Урамда да, транспортта да аска гына карап йөри башладым...

Өч көн үтте, ә вәгъдә ителгән табыш һаман күренми. Инде атна үтеп бара дигәндә, бер көнне хатыным мине эштән май чәчүге кебек балкып каршы алды.

- Нәрсә, - мин әйтәм, - машина оттыңмы әллә?

- Безнең ваучерларыбыз исән икән ләбаса! - диде ул, бер кәгазь сузып. - Тыныч кына табыш китереп яталар икән...

«Әһә! - дим эчтән генә. - Менә кайда икән ул табыш!» Күп еллар элек бер фондка тапшырган ваучерлар турында онытkан да идек инде. Баксаң, ун еллык керемнәрне килеп алырга кушканнар!

Дивиденд дигәннәре артыннан икенче көнне үк йөгердем. Ә андагы чират! Йолдызлар барысына да зур табыш вәгъдә иткән, күрәсең.

Зур акча кирәргә торган кешегә өч сәгать чиратта тору авырмыни?!

Шактый җыелгандыр инде ул ун ел эчендә! Ниһаять, тәрәзә янына җитеп, ниндидер бер горурлык белән кәгазьләрен амбразурага шудырдым да, шатлыклы-тантаналы минутлар кичереп, горур кыяфәттә басып торам. Ә чибәр кыз миңа бөтен утлары белән елмайган кампитрыннан табышымны барлый.

- Менә монда кулыгызны куегыз! - диде ул бераздан, миңа бер кәгазь сузып.

Ул кәгазьгә күз салганымны хәтерлим, калганын - юк: дивиденд суммасын күргәч, һуштан язганмын. Кул куярга дип каләм алырга да өлгермәгәнмен - «ашыгыч ярдәм» машинасы белән алып киткәннәр. Алай да бәхетем бар икән: шул дивиденд инфарктыннан соң да исән калдым!

Ялгышты йолдызлар. Аның каравы, ваучерларның исәнлеген белдек.

Хәер, көтелмәгән җирдән килеп кергән 57 сум дивиденд та чыгым түгел, табыш бит инде.

Юк, ышанам шул йолдызларга. Тагын беркөн алар фаразын укысам, анда: «Атнаның икенче яртысында нәчәлнигегез күзенә чалынып йөрмәгез!» – диелгән. Уйга калдым: ничек аның күзенә чалынмыйча эшләп йөрисең?! Ул безне һәр көн «биш минутлык» дигән бер сәгатьлек киңәшмәгә җыя ич. Шунда күзенә чалынмасаң... Ике мәртәбә кинәшмәдә булмаган Васильевны әнә нишләтте! Алдына бер бит кәгазь салды да: «Алай бик иркенләп йөрисең килә икән, гариза яз!» - диде. Эш белән йөрдем ич мин, дип тә карады. Юк, безнең нәчәлник әйттеме - бетте! Профсоюз түгел, Страсбург суды да яклый алмаячак.

Уйладым-уйладым да, бу юлы да - нишләтәсең, һаман ышанам бит! - йолдызлар сүзенә колак салырга булдым. Ни булса, шул булыр, дип, киңәшмәгә керми башладым. Йөрим шулай нәчәлнигемнең күзенә чалынмаска тырышып. Бер көнне, кичкә табан, яныма үзе килеп кермәсенме!

- Исәнлекме-саулыкмы, әшләр ничек, Шәмсетдинов? - дигән була.

Йөрәгем жу итеп китте. Хәерлегә түгелдер бу.

- Саулыкка зарланган юк, шөкер...

- «Биш минутлык»ларда күренмәгәч, авырыйсыңмы әллә, дип торам...

«Бетте баш! Эштән куа хәзер бу мине!..»

- Ә син болай гына йөрмисең икән. Ярар, йомыш белән мин... Сүз йөртә торган гадәтең юклыкны искә алып, сине атна-ун көнгә оныгым коттеджын салырга булышырга чакырмакчы идем. Әгәр каршы килмәсәң...

Эчкә җылы кереп китте.

- Нинди сүз булырга мөмкин, Фазыл Нигъмәтҗанович?! - мин әйтәм. - Кирәк икән, егерме көнгә дә риза!

Унбиш көн булдым мин ул заманча төзелештә. Кәчкә аягымны сөйрәп кайттым. Хәзер «биш минутлык»ларда көннәр буе утырырга да риза.

Йолдызларга килгәндә, соңгы вакытларда алар алгыша башлады.

Галәмдә дә базар мөнәсәбәтләренә күчеш бара, ахрысы. Әллә алар әйткәннең киресен эшләп карарга микән? Тормышыбыздагы кебек...

**Әхәт САФИУЛЛИН.**

